





# Авылыбыз горурлыгы

922 елда Болгар дәүләтендә Ислам дине кабул ителгән. Шуның белән бәйләнешле рәвештә, Казан ханлыгында бик күп мәчетләр салынган. Әмма, явыз Иван, 1552 елда Казанны яулап алгач, татар халкын руслаштыру, чукындыруны төп максат итеп куйган. Бөтен җирдә мәчет-мәдрәсәләр җимерелгән.

Безнең Дүсмәт авылында да өч мәчет булган. Берсендә — Тулбаев Газимьян, икенчесендә — Габбасов Хәбибулла, өченчесендә-Тулбаев Һади муллалык иткән. Мәчетләр татар халкының дини һәм әхлакый тәрбия үзәге булганнар. XX гасырның утызынчы елларында мәчетләрне сүтәләр, манараларын кисәләр. «Безнең зур булмаган авылыбызда дин кысрыкланган чорда да, динне ташлап бетермәделәр. Җомга намазлары, гает, Мәүлид бәйрәмнәре үткәрелеп килде», — дип искә ала аксакаллар.

Инде соңгы вакытта дингә тугрылыклы халкыбыз иске мәчетләрне яңадан аякка бастыралар, яңаларны төзиләр. 1944 нче елда безнең авылыбыз уртасында да яңа мәчет салынды. Аның манарасы тирә-якка ямь, күңелләргә җылылык биреп, әллә кайдан ук күренеп тора. Бу күркәм мәчет авылыбызның бер бизәге. Аны төзеткән колхоз рәисе хөрмәтенә мәчетне «Мөхтәр мәчете» дип йөртәләр.

2000 нче елда Ырымбур шәһәренең «Хөсәения» мәдрәсәсен уңышлы тәмамлап, үзебезнең мәктәптә укыган укучыбыз Рузилә Хөснулла кызы Мөгаллимә булып авылыбызга кайта. Ул авылдашларына алтын-көмешләрдән кадерлерәк иман байлыгын бирергә тырыша. Күпме кеше «бисмилла» әйтергә, намаз укырга, хәреф танырга, ураза тотарга өйрәнде, әхлак тәрбиясе алды.

Мәчет ишекләре һәрчак ачык. Дин гыйлеме алырга яшьләр дә, олылар да, мәктәп балалары да үз теләкләре белән йөриләр, гарәп графикасын үзләштерәләр, укыргаязарга өйрәнәләр, Ислам тарихы белән танышалар. «Мәчеткә бигрәк тә Адигамов Илмир, Габитов Рәмзил бик теләп йөрделәр,» — дип сөйли мулла Вильдан абый.

Шуның нәтиҗәседер инде, 11 нче сыйныфны тәмамлагач, Илмир Казан шәһәренең Ислам университетына укырга керде.

Ислам динен халкыбызга ирештерергә, җан-тәннәре белән динебезне көчәйтергә, халкыбызны иманга китерергә тырышып йөрүчеләргә рәхмәтебезне белдерәбез һәм изге эшләрендә уңышлар телибез.

**Мөгәлсем АХМЕТВАЛЕЕВА,**
**Дүсмәт авылы,**
**Пономаревка районы.**

# Холкыгыбызны төзәтик!

Пәйгәмберебез Мүхәммәд (гәлийһис-саләтү вәс-сәләм) үзенең хәдис-шәрифендә әйткән: «Дөреслектә гүзәл холыклы кеше, үзенең гүзәл холкы белән, нәфел ураза тотучы һәм кичләрен намазда үткәрүчеләр дәрәҗесенә күтәрелә».

Коръән — кәримдә һәм хәдисләрдә иң күп искә алына торган нәрсә күркәм холыкка чакыручы үгет-нәсыйхәтләрдер.

Чыннан да, күркәм холык бик өстен бер күмаләт. Төннәрен нәфел намазлар уку һәм көндезләрен нәфел уразалар тотуның файдасы шул кешеләрнең үзләре өчен генә булса, күркәм холыкның файдасы башкалар өчен дә була.

Берәүнең күркәм холыклы булуыннан бөтен халык файдалана. Әгәр кеше нәфел гыйбәдәттә булыпта куршесен теле белән рәнҗетсә, аның нәфел гыйбәдәтләрендә файда юк. Чөнки яман холык, балның төмен уксус бозган кебек, гамәлнең савабын боза.

Гүзәл холык халыкларның бәхетләренә, яман холык бәхетсезлекләренә сәбәб булып тора. Пәйгәмбәребез Мүхәммәд ( гәлийһис-саләтү вәс-сәләм) тагын булай әйткән: «Мин күркәм холыкларны тәмам итеп өйрәтү өчен җибәрелдем.» Пәйгәмбәребез Мөхәммәдкә (гәлийһис-саләтү вәс-сәләм) пәйгәмбәрлек килгәнчегә кадәр бер сәламәт милләттә, үзенең әхлагы белән мактанырлык бер җәмгыяттә, гаделлек белән хөкем иткән бер илдә булмаган. Ул вакытта җир йөзендә Персия һәм Рим халкы хөкем иткәннәр. Гарәп халкы бик түбәнчелектә яшәгәннәр. Алар фәхешлеккә баткан булганнар. Хәмер (исерткеч) эчү, отыш уен уйнау, риба ашау, урлау һәм талап алу гадәткә кереп беткән иде. Кыз бала туса, аны исән килеш күмгәннәр. Гөнаһлы эш матур булып саналган. Кагбатулла янәсендә ялан — өс йөрегәннәр. Хәйлә һәм ялган — хикмәт булып, ә хикмәт үзе ахмаклык булып күренгән. Әмма гарәпләр Пәйгәмбәребез Мөхәммәд ( гәлийһис-саләтү вәс-сәләм) тәрбиясе белән әхлакларын төзәткәннән соң өстенлекне алганнар.

Әхлак бозыклыгы йогышлы чир кебек бөтен халыкка таралуы мөмкин.Дөньяда беткән, югалган һәм Аллаһы Тәгаләнең ачуына очраган милләтләрнең һәрберсе әхлак авырлыгы белән авырган кавемнәрдер. Бүгенгесе көндә безнең җәмгыятебездә коточкыч мәсьәләләр артканнан арта бара. Алар — эчкечелек, наркотик белән мавыгу, фахишәлек. Хәзер кешеләр уйга баталар: кайдан икән шундый ахлаксызлык дип? Бу мәсьәлә кешеләрне гасырлар буе борчыды. Котылырга инди генә юллар эзләмәделәр, әмма уңышка ирешә алмадылар. Мисал өчен исерткеч ичүне алыйк. Бу чирне закон белән бетереп карарга тырыштылар. Әмма ичкән кеше, төрле юллар табып, ичүне дәвам итте. Ә кем Аллаһыга ышанып, иман китереп, Ислам кануннары белән яши башлады — ул катгый рәвештә исерткечләрдән киселде. Уңышка ирешү юл ул — динебез Ислам.

Күркәм холыкның изгелек һәм диннең зур бер тармагы икәнлегендә шик юк.

Күркәм холык мөселманның көнккүрүенең төрле ягына кагыла: ул аның сүзләре һәм эшләре, гамәл — гыйбәдәте, халыклар белән мөнәсәбәте.

Ул шулай ук ата —ана хакын, ир — хатын, балалар, туганнар, күршеләр, иптәшләр, ятимнәр һәм башкаларның хакын белү белән бәйләнгән. Амәнәткә тугрылыклы булу, вәгъдәдә тору, дөресне генә сөйләү шулай ук һәрвакыт күркәм холык була. Шушы холыклар һәм башкалары турында Ислам дине өйрәтә.

Уңышка ирешергә һәм эшләребезне төзәтергә, бәхетле булырга һәм сәгадәткә ирешергә уйласак әхлагыбызны төзәтик. Әхлагыбызны төзәтергә теләсәк — динебезгә, Коръән — сөннәткә кайтыйк.

**Имам ИЛДАР хәзрәт,**
**Әсәкәй мәчете.**

# Безне куанычыбыз

2006 елның 3 ноябрь көнендә безнең Иске Әшердә бер зур вакыйга булды һәм авылыбызның чын тарихына керде. Чөнки, ул көнне бездә изге йорт-мәчет ачылды.

Авыл уртасында урнашкан мәчет безнең күңелләргә көч бирә, сөендереп тора. Авылыбызның яше-карты мәчеткә йөриләр. Онытылып барган динебезнең тернәкләнеп килүенә без бик сөенәбез. Ел саен Ураза һәм Корбан гаетләре уздырыла. Хәзерге вакытта җомга намазларына өлкән яшьтәгеләр генә түгел, яшьләребез дә килә башлады.

Мәчетебездә атна саен олыларны һәм уку яшендәге балаларны, авылыбызның дин белүче Нәгыймә апа Газизова Ислам дине кануннары белән таныштыра, гарәпчә укыргаязарга өйрәтә.

Мәчетне салуда бик күп ярдәм итте өлкә Закончыгару депутаты Илдус Ядкәр улы Дәүләтов. Шулай ук мәчетебезне салуда хәләл көчләрен керткән, шушы көндә дин йортыбыз эшләвенә зур тырышлык куеп армый-талмый булышып йөргән кешеләребез: имам-хатыйп Габделвәли Сафиуллин, олы яшьтәге Низамов Үзбәк, Хәбибуллин Нуриәхмәт, Газизов Насих (Үзбәк бабай белән Нуриәхмәт бабай бездән мәңгегә китеп, гүр ияләре булдылар. Аларның изге эшләре безнең күңелләрдә мәңге сакланыр).

Техника һәм төзү материаллары белән булышкан: Венер Газизов, Венер Вәлиев,

Вәсим Баймуратов, Илфак Хәбибуллин, Валерий Шамкаев, Рейзвар Сәмигуллин. Мәчетне агартуда, тирә-якны чистартуда катнашкан барлык авылдашларыбызга «Туган як» гәзите аша меңнән-мең рәхмәтләребезне белдерәбез. Аларга исәнлек-саулык, ныклы сәламәтлек, хезмәтләрендә зур уңышлар, бәхетле киләчәк телибез.

**А.НИЗАМОВ.**
**Матвеевка районы.**

# НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ



| МАРТ | Фаджр Иртә | Восход Кояш чыга | Зухр Ойлә | Аср Икенде | Магриб Ахшам | Иша Ясту |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 7-20 | 8-20 | 14-10 | 17-12 | 19-12 | 20-42 |
| 2 | 7-17 | 8-17 | 14-10 | 17-13 | 19-13 | 20-43 |
| 3 | 7-15 | 8-15 | 14-10 | 17-15 | 19-15 | 20-45 |
| 4 | 7-12 | 8-12 | 14-10 | 17-17 | 19-17 | 20-47 |
| 5 | 7-10 | 8-10 | 14-10 | 17-19 | 19-19 | 20-49 |
| 6 | 7-08 | 8-05 | 14-10 | 17-21 | 19-21 | 20-51 |
| 7 | 7-05 | 8-03 | 14-10 | 17-23 | 19-23 | 20-53 |
| 8 | 7-03 | 8-01 | 14-10 | 17-25 | 19-25 | 20-55 |
| 9 | 7-01 | 7-58 | 14-10 | 17-27 | 19-27 | 20-57 |
| 10 | 6-58 | 7-55 | 14-10 | 17-29 | 19-29 | 20-59 |
| 11 | 6-55 | 7-53 | 14-10 | 17-31 | 19-31 | 21-01 |
| 12 | 6-53 | 7-51 | 14-10 | 17-32 | 19-32 | 21-02 |
| 13 | 6-51 | 7-49 | 14-10 | 17-34 | 19-34 | 21-04 |
| 14 | 6-49 | 7-47 | 14-10 | 17-36 | 19-36 | 21-06 |
| 15 | 6-47 | 7-44 | 14-10 | 17-38 | 19-38 | 21-08 |
| 16 | 6-44 | 7-41 | 14-10 | 17-40 | 19-40 | 21-10 |
| 17 | 6-41 | 7-39 | 14-10 | 17-42 | 19-42 | 21-12 |
| 18 | 6-39 | 7-37 | 14-10 | 17-43 | 19-43 | 21-13 |
| 19 | 6-37 | 7-35 | 14-10 | 17-45 | 19-45 | 21-15 |
| 20 | 6-35 | 7-32 | 14-10 | 17-47 | 19-47 | 21-17 |
| 21 | 6-32 | 7-29 | 14-10 | 17-49 | 19-49 | 21-19 |
| 22 | 6-29 | 7-27 | 14-10 | 17-51 | 19-51 | 21-21 |
| 23 | 6-27 | 7-25 | 14-10 | 17-53 | 19-53 | 21-23 |
| 24 | 6-25 | 7-23 | 14-10 | 17-55 | 19-55 | 21-25 |
| 25 | 6-23 | 7-20 | 14-10 | 17-57 | 19-57 | 21-27 |
| 26 | 6-20 | 7-17 | 14-10 | 17-59 | 19-59 | 21-29 |
| 27 | 6-17 | 7-15 | 14-10 | 18-01 | 20-01 | 21-31 |
| 28 | 6-15 | 7-12 | 14-10 | 18-03 | 20-03 | 21-33 |
| 29 | 6-12 | 7-10 | 14-10 | 18-05 | 20-05 | 21-35 |
| 30 | 6-10 | 7-07 | 14-10 | 18-07 | 20-07 | 21-37 |
| 31 | 6-07 | 7-06 | 14-10 | 18-08 | 20-08 | 21-38 |

**Данные предоставлены Бугурусланским муфтиятом. Возможна разница во времени в сравнении с другими источниками, на 3-5 минут.**